


ГАЗЕТА СЕВЕРО-ЗАПАДА ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ № 13 (28) 13 ИЮЛЯ 2010

ВЕСТИ. СОБЫТИЯ. РЕПОРТАЖИ

# ИЖЕВСК ВСТРЕЧАЛ ГОСТЕЙ

Десятый по счету федеральный Сабантуй прошел 2-3 июля в Ижевске. В нем приняли участие наши соплеменники из более чем 40 регионов страны, в том числе и Оренбургской области. Многочисленные делегации начали прибывать к главному месту празднования — парку имени Кирова — 3 июля с 10 часов утра. У центральных ворот их встречали творческие коллективы Удмуртии, угощая всех желающих традиционным татарским блюдом чак-чак.

А накануне основных торжеств, 2 июля, для гостей Сабантуя был организован праздничный концерт с участием мастеров искусств Удмуртии и Татарстана, который состоялся в театре оперы и балета. Там же по окончанию программы концерта состоялся торжественный прием для гостей федерального Сабантуя от имени Президента УР А.Волкова.

Среди почетных гостей, посетивших народные гулянья, были Президент Республики Татарстан Рустам Минниханов, Президент Удмуртии Александр Волков, заместитель Премьер-министра — министр культуры РТ Зиля Валеева, Председатель Исполкома Всемирного конгресса татар Ринат Закиров, глава Нижнекамского муниципального района Айдар Метшин и другие официальные лица.

В Ижевске побывали спортсмены — борцы из Асекеевского района.



# С МОЛИТВОЙ О ДОЖДЕ

Нынешнее лето, особенно жаркое и скудное на дожди. На полях гибнет урожай. Губернатор области объявил по этому поводу чрезвычайное положение. В этой ситуации, чтобы влага вернулась на землю все действия хороши, в том числе молитва о ниспослании Всевышним — Милостивым и Милосердным — дождя.

Вот такое мероприятие, имеющее столетние корни в традиции народа, было проведено в Асекеевском районе, в ОАО «Алга», по инициативе Генерального директора Ильдуса Давлятова.

Сначала, на месте традиционного проведения сабантуя, состоялся обряд жертвоприношения барана.

Затем аксакалы, около шестидесяти уважаемых сельчан, совершили коллективный намаз. Пока готовилось мясо баранина, аксакалы, в том числе хаджи (люди совершившие паломничество в Мекку), читали аяты и суры Святого Корана.

**На фото:** молитва о дожде.

# АВЫЛ ШӘФКАТЬ ТУТАШЫ

20 июнь медицина хезмәткәрләре үзләренең профессиональ бәйрәмнәрен билгеләп үттеләр.

— Ел саен көтеп алам үзебезнең бәйрәмне, — дип сүзен башлады Тимошкино авылының сәламәт саклау медпункты җитәкчесе Наилә апа.

Наилә Илдар кызы Муфазалова үзенең эшен бик яратып эшли. Авыл халкы аның алтын куллары өчен аңа зур рәхмәтләрен белдерәләр.

Наилә Муфазалова Иске Котлемәт авылында туып үсә. Мәктәпне тәмамлагач Богырыслан шәһәренә медицина училищесына укырга керә һәм фельдшер дипломын кулына алып Матвеевка район хастаханәсендә эшли башлый. Бераздан соң Наиләне туган авылына юнәлеш белән медпунктка эшкә җибәрәләр. Анда ул Азамат егетенә кияүгә чыга һәм Камышлы авылында эшен дәвам итә. Тиздән яшь гаиләгә Тимошкино авылында йорт бирәләр һәм алар шунда күчеп, гөрләтеп гаилә корып җибәрәләр. Бүгенгесе көнне Наилә Илдаровна фельдшер вызыйфасын башкара.

— Эш җиңел түгел. Һәр көн 30 кеше кабул итәм, ә аннары соң чакыруларга йөрим. Соңгы вакытта халык йөрәк, кан басымы чирләре белән еш борчыла, — дип сөйли Наилә апа. Шуңа да авыл шәфкать туташына еш кына йөрергә туры килә. Егерме дәрт ел Н.И. Муфазалова халык исәнлеген саклау эшендә эшли. Яхшы эшләгәне өчен ул рәхмәт хатлары белән бүләкләнде. Ә 2009 елның эш нәтиҗәләре буенча Наилә Муфазалованың исеме район алдынгыларының тактасына куелган. Ул үзенең эше белән бик горурлана.

**Артур НИЗАМОВ,
Матвеевка районы.**

# “ЧИШМӘ” ӨЧЕН ТАВЫШ БИР

19 июнь көнне “Чишмә” фольклор ансамбеле Казанга барып кайтты. Алар Самара өлкәсе, Камышлы районы, Иске Ярмәк авылы “Ак каен” иҗат коллективы белән “Җырлыйк әле” тапшыруында катнашты.

Күпләр яратып карый торган караоке-шоу август аеннан башлап яңа форматта чыга башлый.

Казанга әсәкәйләр милли ризык, милли чигүләр һәм ырынбур шәлләрен алып бардылар. Әлбәттә, моңлы җырларын да онытмадылар. Бәйге кагыйдәләре буенча, алар дүртәү булырга тиеш иде. Беренчесе — туган авыл турында, икенчесе — халык җыры, өченчесе — ретро җыр һәм азакы — караокега кушылып җырлана торган җырлар.

Килгән ансамбелләрне жюри хөкем итте. Жюри әгъзалары — танылган шәхесләр: Г.Камал исемендәге театрның директоры Шамил Закиров, композитор Рим Гатауллин һәм шагыйрә Шагыйрҗанова. Нәтиҗәдә, “Чишмә” белән “Ак каен” икесе дә 39 балл җыйдылар, ә җиңүчене тамашачыларга сайлап алырга тәкъдим итеlә. Августта тапшыру эфирга чыккач, авылдашлар өчен тавыш бирергә була.

**Алсу ХАФИЗ.**